| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан<br>Иляксазское сельское<br>поселение Сармановского<br>муниципального района** | **Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Илексаз<br>авыл җирлеге** |

---

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>5 нче октябрь 2016 ел | **КАРАР**<br>**№ 16** |

Илексаз авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Илексаз авыл җирлеге Уставының 11 ст., Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ.:

1. Илексаз авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябренә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслarга:

"2017 елда Илексаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү, шул исәптән 20,0 мең сум:

- Илексаз авылының Үзәк урамы буенча 20 мең сум күләмендә янгын сулыгын тирәнәйтү;

2) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларга 60,0 мең сум күләмендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән:

- Мортышбаш авылы Яр Буе урамына 20 мең сум күләмендә вак таш җәю;

- Октябрьнең 70 еллыгы урамында 20 мең сум күләмендә вак таш җәю;

- трактор өчен 10 мең сум күләмендә ягулык-майлау материаллары һәм запас частьлар сатып алу;

- тракторчы өчен хезмәт хакы 10 мең сум;

3) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән 5,0 мең сум күләмендә, шул исәптән:

- Илексаз, Мортышбаш авылларында мәдәни чаралар үткәрү өчен 5,0 мең сум күләмендә бүләкләр алу;

4) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту) 25,0 мең сум күләмендә, шул исәптән:

- Мортышбаш авылының торак пункты исемен, урам күрсәткечләрен һәм йорт номерлары белән 7,0 мең сум күләмендә урнаштыру ;

- авыл җирлегенең Комсомол урамы, 2 нче йорт адресында урнашкан Илексаз авылы күрсәткечләре стендын 4,0 мең сум күләмендә рәсмиләштерү;

- Илексаз, Игәнә-Баш, Мортышбаш авылларында урамнарны яктырту 14,0 мең сум күләмендә;

Барлыгы 110,0 мең сум.

ӘЙЕ ЮК ".

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Илексаз авыл җирлеге
Советы рәисе Ф.М.Гильфанов